| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>ШЛАНГОВСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ<br>ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ШЛАНГА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

с. Шланга

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

20 октябрь 2023 ел № 31/2

Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлеге Советының

"Физик затлар милкенә салым турында" карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлегенә, Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлеге Уставына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

**1.** Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлеге Советының «Физик затлар милкенә салым турында " 15.11.2019 № 45/3 карарына (22.05.2020 № 49/5, 15.11.2022 №21/3 редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

**4 нче пунктны түбәндәге эчтәлектәге 4- 7 нче пунктчалар белән тулыландырырга:**

"4) махсус хәрби операциядә катнашучылар, шул исәптән һәлак булганнар, махсус хәрби операция барышында хәбәрсез югалганнар;

5) махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзалары (тормыш иптәше (хатын), балигъ булмаган балалар, ата-аналар һәм башка эшкә сәләтсез тәрбияләнүчеләр);

6) Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» гы Указына ярашлы рәвештә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, шул исәптән махсус хәрби операция барышында хәбәрсез югалган һәлак булганнар;

7) Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар гаилә әгъзалары (тормыш иптәше

(хатыны), балигъ булмаган балалар, ата-аналар һәм башка эшкә сәләтсез тәрбияләнүчеләр).».

**2.**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы шланг авыл җирлеге Советының «Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлеге Советының «Физик затлар милкенә салым турында»карарына үзгәреш кертү хакында»2022 елның 15 ноябрендәге 21/3 номерлы карары үз көчен югалткан дип танылсын.

**3.** Әлеге карарны Шланга авыл җирлегенең мәгълүмати стендларына, Шланга авыл җирлеге сайтына урнаштырырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

**4.** Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

**5.** Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлеге Советының 2019 елның 15 ноябрендәге 45/3 номерлы карарының,  4-7 пунктлары һәм 4.1 пунктлары нигезләмәләренең гамәлдә булуы (әлеге карар редакциясендә) 2022 елның салым чорында физик затлар милкенә салымны исәпләү белән бәйле хокукый мөнәсәбәтләргә һәм аннан соңгы салым чорларына кагыла.

Глава Шланговского сельского поселения
Дрожжановского муниципального
района Республики Татарстан: И.И.Якупов